**Татарстан Республикасы**
**Кукмара муниципаль районы**
**Нырья авыл башкарма комитеты**

# КАРАР

«27» февраль 2023 ел № 6

Нырья авыл башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 19 декабрендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярилык (волонтерлык) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 7 октябрендәгендәге 394-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Кукмара муниципаль районы Нырья авыл башкарма комитеты карар бирә:

1. Нырья авыл башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 19 декабрендәге 7 номерлы карарына (2022 елның 24 октябрендәге 46 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырыла:

«- медицина ярдәме күрсәтүче оешмаларда медицина ярдәме күрсәтүдә ярдәм итү;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә эчке эшләр органнарына (полиция) һәм башка хокук саклау органнарына җәмәгать тәртибен саклауда булышлык күрсәтү.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Нырья авыл башкарма
комитеты җитәкчесе В.В. Васильев

ОГРН 1061675010935
ИНН 1623008426